**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКИСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ШИЛЬНЕБАШ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«29»апреля 2019 Шилнәбаш авылы № 27

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шильнебаш авыл җирлеге милке турында мәгълүматны ачу хакында нигезләмәне раслау турында

Муниципаль милекне нәтиҗәле һәм рациональ файдалану максатында,Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге милке турында мәгълүматны ачу хакында нигезләмәнекушымтадагыча расларга.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (http://tukay.tatarstan.ru) «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе О.А. Гончарова

Тукай муниципаль районы Шильнебаш авыл җирлеге Башкарма комитетыны 2019 елны 29 апреля №27 санлы карарына кушымта

# Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шильнебаш авыл җирлеге милке турында мәгълүматны ачу хакында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районыШильнебаш авыл җирлеге милке турында мәгълүматны ачу хакында нигезләмә «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ санлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ санлы Федераль закон, «Муниципаль сер турында» 1993 елны 21 июлендәге 5485-1 санлы карары нигезендә эшләнгән һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районыШильнебаш авыл җирлегенең муниципаль милке турында мәгълүмат составын, шулай ук аны ачу тәртибен һәм срокларын билгели (шул исәптән аерым милек объектлары буенча).

1.2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районыШильнебаш авыл җирлегенең муниципаль милке турында мәгълүматны ачу дигәндә аның белән кызыксынучы барлык кешеләрнең дә мәгълүматтан файдалана алуын тәэмин итү аңлашыла.

1.3. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районыШильнебаш авыл җирлегенең муниципаль милкен исәпкә алу объектлары турында мәгълүмат Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районыШильнебаш авыл җирлеге Башкарма комитетыҖитәкчесе тарафыннан муниципаль норматив хокукый актларда бирелә. Мәгълүмат бирүдән баш тарту соратып алына торган мәгълүматта дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматлар булу очрагында мөмкин.

1.4. Юридик затлар мәнфәгатьләренә зыян китереп мәгълүмат куллану Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында каралган җаваплылыкка китерә.

1.5. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шильнебаш авыл җирлегемуниципаль милке турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районыШильнебаш авыл җирлеге милек реестрында теркәлгән мәгълүматлар, шулай ук Тукай муниципаль районы Шильнебаш авыл җирлегемилкендәге җир кишәрлекләре турындагы мәгълүматлар күләмендә бирелә.

1.6. Татарстан Республикасының Шильнебаш авыл җирлегемуниципаль милке турындагы мәгълүматны ачу мәгълүмат тарату һәм кызыксынган затларга мәгълүмат бирү рәвешендә гамәлгә ашырыла.

Мәгълүмат тарату массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару һәм «Интернет» челтәрендә сайтта урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла. Мәгълүмат

бирү кызыксынган затларның язма мөрәҗәгатьләре буенча, шул исәптән аерым милек объектлары буенча да гамәлгә ашырыла.

## 2. Мәгълүмат тарату

2.1. «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы сайтында урнаштыру юлы белән таратыла торган муниципаль милек турында мәгълүмат түбәндәге мәгълүматлар исемлеге белән билгеләнә (мондый мәгълүматлар закон белән чикләнгән мәгълүматны үз эченә алган очраклардан тыш):

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районыШильнебаш авыл җирлегенең муниципаль учреждениеләре исемлеге (исеме, урнашу урыны);

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районыШильнебаш авыл җирлегенең муниципаль унитар предприятиеләре исемлеге (исеме, урнашу урыны);

устав капиталы өлешләре (акция пакетлары) Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районыШильнебаш авыл җирлеге милкендә булган хуҗалык җәмгыятьләре исемлеге (хуҗалык җәмгыятенең исеме, урыны, устав капиталында Тукай муниципаль районы Шильнебаш авыл җирлегеөлеше);

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шильнебаш авыл җирлегемилкендә булган күчемсез мөлкәт (биналар, бүлмәләр) исемлеге (исеме, урнашу урыны, мәйданы, максатчан билгеләнеше, куллануны чикләү, өченче затларның хокукларын йөкләү);

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шильнебаш авыл җирлегемуниципаль милкен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы);

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районыШильнебаш авыл җирлегенең муниципаль милкен хосусыйлаштыру прогноз планы (программасы) үтәлеше турында хисап.

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районыШильнебаш авыл җирлегенең муниципаль милке турында күрсәтелгән мәгълүмат шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыгарга мөмкин.

2.2. Әлеге нигезләмәнең 2.1 пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар, финанс елы тәмамланганнан соң, дүрт айдан да соңга калмыйча, Тукай муниципаль районының рәсми сайтында 1 январь торышына ел саен бастырылып чыгарга тиеш.

2.3. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районыШильнебаш авыл җирлегенең муниципаль милкендә булган мөлкәт объектлары турында мәгълүматны ачу, аларны хосусыйлаштыру белән бәйле рәвештә, хосусыйлаштыру турында законнар белән билгеләнгән күләмдә гамәлгә ашырыла.

## 3. Кызыксынган затларга мәгълүмат бирү

3.1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районыШильнебаш авыл җирлегенең муниципаль милке реестрында теркәлгән аерым милек объектлары (алга таба – исәпкә алу объектлары) буенча мәгълүмат кызыксынган затларның мөрәҗәгате буенча хат рәвешендә яисә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль

районы Шильнебаш авыл җирлегенең муниципаль милке реестрыннан өземтә рәвешендә бирелә.

3.2. Исәпкә алу объектлары турында мәгълүмат (яки аны бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән карар) Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районыШильнебаш авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе тарафыннан мөрәҗәгать теркәлгән көннән алып 30 көн эчендә бирелә.

3.3. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районыШильнебаш авыл җирлегенең муниципаль милек реестрыннан өземтәләр түбәндәгеләргә бирелә:

исәпкә алу объектлары хокук ияләренә яки аларның законлы вәкилләренә;

исәпкә алу объекты хокук иясеннән яки аның законлы вәкиленнән ышанычнамә алган физик һәм юридик затларга;

Россия Федерациясе Хисап палатасы, Татарстан Республикасы Хисап палатасы, Тукай муниципаль районы Контроль-хисап палатасына;

җирле үзидарә органнарына һәм Татарстан Республикасының, Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт хакимияте органнарына;

дәүләт хакимиятенең федераль органнарына, шул исәптән:

күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы органнарга;

салым органнарына;

судларга, хокук саклау органнарына, исәпкә алу объектлары һәм (яки) аларның хокуклары белән бәйле эшләре булган суд приставларына-башкаручыларга;

федераль монополиягә каршы органга һәм Татарстан Республикасында аның территориаль органына.

3.4. Әлеге нигезләмәнең 3.3 пунктында күрсәтелмәгән кызыксынган затларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районыШильнебаш авыл җирлегенең муниципаль милке реестрында исәпкә алу объектлары барлыгы турында гына мәгълүмат бирелә.

3.5. Соратып алынган мәгълүматны бирүдән баш тарту (язма формада бирелә) нигезләнергә тиеш.

Соратып алынган мәгълүматны бирүдән баш тарту өчен нигез булып түбәндәге сәбәпләр тора:

мөрәҗәгатьтә законнар белән чикләнгән мәгълүматны үз эченә алган мәгълүматлар сорала;

мөрәҗәгатьнең эчтәлеге объектны билгеләргә мөмкинлек бирми;

мөрәҗәгатьтә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районыШильнебаш авыл җирлегенең муниципаль милке реестрында мәгълүматлар булмаган мөлкәт объекты күрсәтелгән.